Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлеге составына керүче Яңа Кокшаны авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар

2022 елның «17» декабре №5

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы нигезендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында», «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлеге Советының 2019 елның 4 октябрендәге 120 номерлы карары нигезендә, 2022 елның 21 декабрендә 13.00 сәгатьтә узган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлегенең Яңа Кокшаны авылында гражданнар җыенының түбәндәге мәсьәләләре буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде:

“2023 елда Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлегенең Яңа Кокшан авылында теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә гражданнардан үзара салым җыюны гамәлгә кертергә, балигъ булмаган балаларын тәрбиядә тотучы күпбалалы гаиләләр һәм көндезге уку формасы студентлары, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнарга, әлеге категориядәге гражданнар өчен 500 сум күләмендә, Россия Федерациясе Хәрби көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларын, I и II группа инвалидларны түләүдән азат итәргә һәм Үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә дигән сорауга ризалылыгыз бармы дигән сорауга карар кабул ителде:

1.Зиратка чүп савытлары алу

2.Җәй көне үләннәрне чабу

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 58 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 31.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" 31 граждан тавыш бирде;

"ЮК" 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнары җыены КАРАР КЫЛДЫ:

Менделеевск районының Монаш авыл җирлеге Яңа Кокшан авылында гражданнар җыенын узган дип таныргa, җыен нәтиҗәләре дөрес дип санарга.

“2023 елда Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлегенең Яңа Кокшан авыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә гражданнардан үзара салым җыюны гамәлгә кертергә, балигъ булмаган балаларын тәрбиядә тотучы күпбалалы гаиләләр һәм көндезге уку формасы студентлары, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнарга, әлеге категориядәге гражданнар өчен 500 сум күләмендә, Россия Федерациясе Хәрби көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларын, I и II группа инвалидларны түләүдән азат итәргә һәм Үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә дигән сорауга ризалылыгыз бармы дигән сорауга карар кабул ителгән дип санарга:

1.Зиратка чүп савытлары алу

2.Җәй көне үләннәрне чабу

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Монаш авыл җирлеге» бүлегендә

урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Монаш авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Иосифов